**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы  Яңа Тинчәле авыл җирлегенең   Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең   Яңа Тинчәле   авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы гражданнары җыенының 2023 елның 1 ноябрендәге 1нче номерлы  карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

«2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны тоту, җәйге вакытта территорияне  чабу  (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), Яңа Тинчәле авылында хуҗасыз йорт хуҗалыкларын койма белән әйләндереп алу),

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Яңа Тинчәле авылында  каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыгын төзекләндерү).”.

2. Җыен нәтиҗәләрен  Яңа Тинчәле  авыл җирлегенең  Яңа Тинчәле авылында  махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,

Яңа Тинчәле   авыл җирлеге башлыгы _________  Р.К. Мадышев

Халык җыены секретаре _________  Г.Ш. Хәсәнова